беркадәр фонетик һәм морфологик язылыш традицияләрен саклыйлар. Лексика ягыннан татар тел байлыгы тотрыклы саклана, шулай ук текстларда гомумтөрки лексиканың күп булуы күзәтелә.


**Әдәбият**

Әхмәтҗанов, М.И. Татар халкының борынгы ырым-арбаулары һәм төрле фалнамәләре. – Казан : РТ ФА Тарих институты нәшрияты, 2012. – 271 б.

Әхмәтҗанов, Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001, – 272 б.

Бакиров, М.Х. Татар фольклоры: Югары уку йортлары өчен д-лек / М.Х. Бакиров. – Казан: Мәгариф, 2008. – 359 б.

Татар халык сөйләшләре: Ике китапта: Беренче китап / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б. – Казан: Мәгариф, 2008. – 463 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты нәшрияты, 2005. – 848 б.

Тумашева, Д.Г. Татарский глагол. Опыт функционально-семантического исследования грамматических категорий. – Казань: Изд-во КГУ, 1986, – 189 с.

Древнетюркский словарь. – Ленинград: Изд-во «Наука», 1969. – 676 с.



***Мортазина Ләлә Рәисовна***

ТР ФА нең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Казан


## АБДУЛЛА ӘСӘДУЛЛИН – КҮРЕНЕКЛЕ МЕТОДИСТ


*В статье рассматривается педагогическая деятельность видного татарского ученого и методиста, автора учебников татарского и русского языков, внесшего огромный вклад в развитие методики преподавания русского языка в национальной школе и татарского языка в русскоязычной аудитории А.Ш. Асадуллина.*



**Ключевые слова**: *татарский язык, русский язык,методика, учебники,развитие речи, активные методы, аудирование, диалогическая речь, монологическая речь, методическое наследие.*



*The article considers pedagogical activity of the famous Tatar scientist and methodologist A.Sh. Asadullin. He is the author of many textbooks of the Tatar and Russian languages. A.Sh. Asadullin has made a huge contribution to development* of methods of teaching the Russian language in the Tatar School and the Tatar language in Russian-speaking audience.*He has created the technique based on development of oral speech.*



**Key words:** *Tatar language, Russian language, technique, textbooks, development of the speech, active methods, audition, dialogical speech, monological speech, methodical heritage.*


Татарстанда дәүләт телләрен үстерү, саклау һәм өйрәнү – республика сәясәтендәге иң актуаль юнәлешләрнең берсе [Государственная...]. Белем

бирү системасының барлык баскычларында рус һәм татар телләрен укытуны тиешле дәрәҗәгә күтәрү, предметларны ана телендә укыту, татар теле буенча һәм татар телендә төрле дәрәҗәдәге камил дәреслекләр, методикалар булдыру – XX гасырның 90 нчы елларыннан соң мәгариф үсешен билгеләүче факторларның әһәмиятлеседер, мөгаен. Бу мәсьәлә, соңгы чорда бик заманча яңгыраш алса да, яңа түгел. Рус телле укучыларга һәм татарларга татар телен укыту проблемасы танылган галимнәребез И. Хәлфин, М. Мәхмүдов, К. Насыйри һ.б. хезмәтләрендә күтәрелсә, татарларга рус телен укыту бигрәк тә җәдитчелек хәрәкәте таралу белән актуальләшеп, революциядән соң аеруча югары баскычка куела. Күренекле татар педагоглары М. Корбангалиев, Х. Бәдигый, Р. Газизов һ.б.ның татарларга рус теле, рус телле укучыларга татар теле укыту методикасына караган күп санлы хезмәтләре, дәреслек һәм кулланмалары озак вакытлар мәктәп системасында кулланылып килде. XX гасырның икенче яртысыннан соң милли мәктәптә рус телен, 90 нчы еллардан соң башка милләтләргә татар телен укыту методикасы фәне үсешенә шактый зур өлеш керткән, балаларга тел өйрәтүдә уңышка ирешү мөмкинлеген биргән үзенчәлекле укыту алымнарын булдырган күренекле педагоглар арасында педагогика фәннәре докторы, профессор, ТР ның атказанган фән эшлеклесе Абдулла Шаһи улы Әсәдуллин да бар.

Абдулла Әсәдуллин 1926 елның 28 ноябрендә Зөя кантоны (хәзерге Яшел Үзән районы) Күгеш авылында дөньяга килә. 1942 елда Казан шәһәре 29 нчы мәктәбенең 7 сыйныфын тәмамлап, Казан авиация техникумында белем алган егетне язмыш Үзбәкстан ССРның Нәманган шәһәренә китерә. Биредә ул укытучылар институтын (1950), 1952 елда исә Ташкент педагогия институтын тәмамлый. Берничә ел дәвамында яшь белгеч Нәманган шәһәре мәктәпләрендә балалар укыта. 1957 елда туган якларга әйләнеп кайту белән, телләр укытуда беркадәр тәҗрибә туплаган, милли мәктәптә рус телен укытуның торышын яхшырту теләге белән янган Абдулла Шаһи улы, проблеманы фәнни яктан өйрәнү өчен, Казан шәһәрендәге Татар укытучыларның белемен күтәрү институтына эшкә урнаша. Биредә методист, ә 1958-1963 елларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында, 1963-1991 елларда Милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү институтының Татарстан филиалында өлкән фәнни хезмәткәр булып эшли. 1993 елдан соңгы хезмәт эшчәнлеге ТР ФА нең Тарих институты каршындагы Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге белән бәйле. Биредә ул әйдәп баручы хезмәткәр вазифасын башкара.

Абдулла Шаһи улының эшчәнлеге, инде билгеле булганча, беренче чиратта, татар балаларына рус телен өйрәтүнең методик нигезләрен булдыруга багышланган. Аның күп санлы дәреслекләре, методик әсбаплары һәм сүзлекләре озак еллар дәвамында мәктәптә кулланылды һәм кулланыла [Асадуллин, 1959, 1970]. Гомуми лингводидактика фәне үсешенә сизелерлек өлеш керткән әлеге хезмәтләр тиешенчә бәяләнде.

А.Ш. Әсәдуллинның фәнни-педагогик эшчәнлегенең икенче юнәлеше - рус телле аудиториядә татар телен укыту мәсьәләләре. 90 нчы еллардан алып татар телен дәүләт теле буларак укыту барлык уку йортларына да кертелде, дәреслекләр әзерләнде, методикалар булдырылды, әмма, кызганычка каршы, башка милләт вәкилләре арасында татар телен белүчеләр саны артмады. А.Ш. Әсәдуллин әлеге проблемага багышланган бер мәкаләсендә: «Иң актуаль сорау – ни өчен без, рус балаларына 11 ел дәвамында (балалар бакчаларын да исәпкә алсак 14 ел) татар телен укытып та, берничек тә аларны икенче дәүләт телендә сөйләшергә өйрәтә алмыйбыз?» дигән сорауны куя [Асадуллин, 2001: 14]. Галим берничә сәбәпне аерып күрсәтә. Беренчесе, аның карашынча, балаларны чит телгә өйрәтә башлауның вакыты дөрес билгеләнергә тиеш. Нәниләрне икенче телгә күнектерү өчен иң кулай чор – ул 3-4 яшьлек вакыт. Тик мәктәпкәчә яшьтәге балаларны татар теленә өйрәтү өчен уңышлы әсбапларның булмавы әлеге мәсьәләне хәл итүгә комачаулык ясый. Икенче мәсьәлә, галим фикеренчә, методик яктан уйланылган камил системаның булмавы белән бәйле. «Бар нәрсәгә өйрәтәбез: укырга да, язарга да, татар теленең грамматикасына да; ләкин рус балаларын беренче чиратта татарча сөйләшергә кирәклеген онытабыз» [Асадуллин, 2001: 15]. А. Әсәдуллинның карашынча, әлегә кадәр кулланылган методикалар һәм дәреслекләр нигездә татар теленең кагыйдәләрен, закончалыкларын өйрәтүгә юнәлдерелгән. «Ике дистә ел дәвамында рус телле укучыларның татар телен өйрәнә алмаулары безнең аларны татар сөйләменә түгел, ә татар теленә өйрәтүебездә. Укырга, язарга, грамматик кагыйдәләргә өйрәтәбез, ләкин тере татар сөйләменә – татар телендә сөйләшкәнне аңларга, диалоглар төзергә, текстка таянмый гына бәйләнешле сөйләм төзергә өйрәтмибез. Дәреслек белән генә эшләп, без балаларны беркайчан да татар сөйләменә өйрәтә алмаячакбыз. Сүзләр, кагыйдәләр өйрәнеп, текстлар укып кына сөйләм эшчәнлегенә кушылу мөмкин түгел», – дип язды ул [Асадуллин, 2004: 4]. Дәреслекләр өчен махсус язылган методик кулланмаларның булмавы да эшкә комачаулык ясый, дип ассызыклый А. Әсәдуллин.

А. Әсәдуллинның рус балаларын татарча сөйләшергә өйрәтү өлкәсендә башкарылган иң зур хезмәтләренең берсе – рус мәктәпләренең 5-11 нче сыйныфлары өчен язылган «Татар сөйләме» әсбапларыдыр, мөгаен [Асадуллин, 2002]. Алар галимнең методик принципларын күздә тотып, һәм, авторның үзе билгеләвенчә, укытучылар өчен гамәлдәге татар теле дәреслекләренә өстәмә методик кулланма буларак әзерләнгән [Асадуллин, 2004: 3]. Әсбапларда укучыларны татар сөйләменә (тыңлап кабул итү, диалогик һәм монологик сөйләм) өйрәтү өчен системага салынган материаллар тәкъдим ителә.

Педагог дәрестә рус телле балалар белән шөгыльләнгәндә актив алымнарны (текстларны уку – пассив алым) куллану кирәклегенә басым ясый.

Бер үк вакытта дәреслекләрдәге тектларның балаларны кызыксындырырлык, шул ук вакытта артык катлаулы булмавын («кайвакыт аларны телне бик яхшы белүче кеше дә аңлап бетерә алмый») төп шарт итеп куя. Дәреслекләрдә татар язучыларының әсәрләреннән өзекләр мөмкин кадәр күбрәк булырга тиеш, чөнки алар тере татар сөйләмен үзләштерергә ярдәм итәләр [Асадуллин, 2001: 16]. Ул рус телле балаларга фәлсәфи характердагы текстларны бирүгә каршы килде, тел өйрәнү өчен тәкъдим ителгән материал аңлаешлы, төгәл һәм җанлы булырга тиеш дип санады [Асадуллин, 2004: 6]. Тел өйрәнүдә, галимнең карашынча, тере тел тирәлегенә керү мөһим, чөнки «елгага керми генә берәүне дә йөзәргә өйрәтеп булмый» [Асадуллин, 2004: 7]. Димәк, телне үзләштерүдә төп максат – ул кешене аралашырга, җанлы сөйләм теленә өйрәтү.

А. Әсәдуллин – татар методика фәненең тарихына багышланган хезмәтләр авторы да. Аның «Татар мәктәбендә рус телен укыту тәҗрибәсе тарихыннан. Методик мирас» дигән китабында бу өлкәдә эшләгән атаклы галим һәм белгечләребез – М. Корбангалиев, Н. Дмитриев, В. Чистяков һ.б. эшчәнлегенә җентекле анализ ясалган. Аның икенче бер китабы [Асадуллин, 2001] шулай ук милли мәктәптә рус телен укытуның тарихына багышланган.
Гомерен халкына, туган телен саклауга, башка милләтләрне татар теленә, татарларны рус теленә өйрәтүгә багышлаган галим һәм педагог Абдулла Әсәдуллин республикабызда яшәүче һәр кеше ике дәүләт телен – татар һәм рус телләрен бер үк дәрәҗәдә камил белергә тиеш дип санады һәм бу фикерен үзенең күпсанлы хезмәтләре һәм эшчәнлеге белән раслады. Аның эшен бүген укучылары дәвам итә.

Абдулла Шаһи улы Әсәдуллин 2004 елның 7 маенда вафат булды.

**Әдәбият**

Асадуллин, А.Ш. Учебник русского языка. Для татарской школы. Ч. 1. / А.Ш. Асадуллин. – Казань: Таткнигоиздат, 1959. – 292 с.

Асадуллин, А.Ш. Методическое руководство к «Букварю». Книга для учителя / А.Ш. Асадуллин. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1970. – 135 с.

Асадуллин, А.Ш. Знай татарский ты язык, знай и русский ты язык...: Основы методики татарского языка в начальной татарской школе / А.Ш. Асадуллин. – Казань: Магариф, 1997. – 311 с.

Асадуллин, А.Ш. Заглядывая в прошлое методической науки / А.Ш. Асадуллин. – Казань: Мастер Лайн, 2001. – 255 б.

Асадуллин, А.Ш. Актуальные вопросы преподавания татарского языка в русскоязычной аудитории / А.Ш. Асадуллин // Национальная школа и актуальные проблемы обучения. – Казань: «Мастер Лайн», 2001. – С. 14 – 16.

Асадуллин, А.Ш. Татарская речь. Пособие для учителей, работающих с русскоязычными учащимися. 5 класс / А.Ш. Асадуллин. – Казань: Магариф, 2002.– 229 с.

Асадуллин, А.Ш. Методическое руководство к пособиям «Татарская речь» для 5-11 классов русских школ / А.Ш. Асадуллин. – Казань: Алма-Лит, 2004. – 47 с.

Әсәдуллин, А.Ш. Татар теле (рус телендә сөйләшүче балалар өчен) / А.Ш. Әсәдуллин. – Казан: Мәгариф, 1996. – 214 б.

Әсәдуллин, А.Ш. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту методикасы нигезләре (автордаш – Юсупов Р.А.) / А.Ш. Әсәдуллин, Р.А. Юсупов. – Казан: Мәгариф. – 1998. – 151 б.
Государственная программа «Сохранение, изучение и развитие государственных языков Республики Татарстан и других языков в Республике Татарстан на 2014 – 2020 годы» // docs.cntd.ru/document/463305579.

***Мөгътәсимова Гөлназ Ринатовна***
Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан

## ТАТАР ҺӘМ УЙГЫР МӘКАЛЬЛӘРЕНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Статья посвящена изучению некоторых особенностей паремий татарских и уйгурских языков. Сопоставительный анализ паремий проводится с целью выявления лингвокультурно-национальных специфик паремий. Автор приходит к выводу, что паремии занимают важное место в жизни народа и позволяют больше узнать о его культуре.*

**Ключевые слова:** *татарский язык, уйгурский язык, паремия, менталитет, картина мира.*

*The article is devoted to the study of some features of proverbs Tatar and Uyghur languages. Comparative analysis of proverbs is conducted to identify Lingvokulturnaja-national specificities of parmemy. The author concludes that paremias occupy an important place in the life of the people, and let you know more about its culture.*

**Key words:** *Tatar language, Uygur language, proverbs, mentality, world view.*

Гомумән алганда, татар һәм уйгыр мәкальләренең тематикасы охшаш. Мәсәлән, *Ачның күзе икмәктә, тукның күзе хикмәктә* мәкале уйгырча болай яңгырый: *Ачның көзе нанда, токның көзе хикметте.* Шулай итеп, татар һәм уйгыр мәкальләренең төзелешендә һәм тематикасында күп уртаклыклар табыла. Мәкальләрнең тематикасын карасак, шактый охшаш темаларга юлыгырга мөмкин: «Кеше һәм җәмгыять», «Балалар һәм ата-аналар», «Табигать», «Яхшылык һәм яманлык».

Ике халыкның мәкальләре кыска, тотрыклы һәм сүз сәнгатен тәшкил итә, киң кулланыла.

Татар һәм уйгыр мәкальләренә аларның ике өлештән торуы хас. Чыннан да, мәкальләр ике өлештән тора, әмма һәммәсе дә түгел. Мәсәлән, *Ике куян койрыгын берьюлы тотам димә*; *Ана сүт бәргән Вәтиниңгә муһәббәт бағла (Анаң сөт биргән Ватанны ярат); Йомырка тавыкны өйрәтми; Ана Вәтиниң – алтун бөшүк (Ватан Ана – алтын бишек)* – бер өлештән генә тора торган мәкальләр. Алга таба без өч яки дүрт өлештән